ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 3 өлешендәге «е» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«е) каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру;»;

2) 9 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктның «в» пунктчасында «көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм яңадан эшкәртү» сүзләрен «каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

3) 18 статьяның 5 өлешендә:
а) 3 пунктта «яңа» сүзен төшереп калдырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:
«4) җирлекнең, шәһәр округының коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларына, җирлекнең, шәһәр округының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына, җирлекнең, шәһәр округының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына.»;

4) $19^1$ статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю), транспорт белән ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү объектлары;»;

5) $19^2$ статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю) һәм транспорт белән ташу объектлары;»;

6) $19^3$ статьяның 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю), транспорт белән ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү объектлары;».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең бүтән срогы билгеләнгән нигезләмәләрдән гайре, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 2, 4 – 6 пунктлары 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 22 апреле
№ 28-ТРЗ